| | | |
|---|---|---|
| УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

__28.07.2022__ Казан шәһәре № 01-05/ 187 - пр

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары нигезендә

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең

административ регламентын раслау хакында» 2020 елның 9 декабрендәге 01-05/190-пр номерлы;

«Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2020 елның 9 декабрендәге 01-05/190-пр номерлы боерыгы белән расланган Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 10 декабрендәге 01-05/319-пр номерлы.

3. Күзәтчелек һәм автоматлаштырылган рәвештә исәпкә алу бүлегенә әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталында Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе сайтында, «Документлар» бүлегенең «Административ регламентлар» бүлекчәсендә урнаштырырга.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче Р.Р.Зыятдинов

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең _28.07.2022__№01-05/187-пр боерыгы белән расланды

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең (алга таба – Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе) административ процедураларны һәм административ гамәлләрне башкару стандартын, тәртибен һәм эзлеклелеген билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: физик зат, шәхси эшкуар яки юридик зат (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Вәкаләтләрен таныклый торган документ яисә законнар нигезендә Мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итә торган башка затлар (законлы вәкилләр) (алга таба – Мөрәҗәгать итүченең вәкилләре).

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Күзәтчелектәге машиналар һәм җайланмалар хуҗаларының сатылган яки төзекләндерелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавы турындагы ризасызлыкларын карау комиссияләрендә катнашу.

### 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

Дәүләт хезмәте Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең территориаль бүлекләре аша (алга таба – бүлекләр (Идарә бүлеге)) тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) аша дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирү һәм мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап КФҮ мөрәҗәгать иткәндә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү өлешендә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны соратып алудан баш тарту турында карар КФҮ кабул ителми.

## 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) Төп нәтиҗәләр, техниканы торгызу чыгымнары, чыгымнарны түләү өчен җаваплы як, җитештерүче предприятие (тәэминатчы) тарафыннан китертелергә тиешле детальләр, төеннәр һәм агрегатлар номенклатурасы булган дәгъваны карау акты (алга таба – дәгъваны карау акты). Акт өч нөсхәдә төзелә.

2) Дәгъваны карау актының дубликаты.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен түбәндәге ысуллар белән ала:

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә һәм Идарә бүлекләренә шәхсән барып;

көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен дә (алга таба – «Интернет» челтәре) кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат - телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы (https:// www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы (https://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Республика порталы) аша.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

Дәүләт хезмәте гариза һәм документлар теркәлгәннән соң, эш көннәрендә исәпләнгән 7 көнлек срокта күрсәтелә.

Дәгъваны карау актының дубликатын бирү гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1. Дәгъваны карау актын алу өчен:

1) гариза:

кәгазь чыганактагы документ формасында (әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә). Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә һәм Идарә бүлекләренә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин;

Бердәм портал яки Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләренә туры китереп имзаланган электрон рәвештә (тиешле мәгълүматларны гаризаның интерактив формасына кертү юлы белән тутырыла). Гариза формасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең рәсми сайтында күчермәсен алу һәм тутыру өчен электрон формада урнаштырылган;

2) мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклаучы документ;

4) үзйөрешле машина паспорты яки машинага милек хокукын раслаучы башка документлар;

5) гарантия талоны сервис кенәгәсе;

6) товар кәгазе;

7) эксплуатация документлары (эксплуатацияләү буенча куллану кагыйдәләре, эксплуатацияләү буенча кулланма, техник хезмәт күрсәтү буенча кагыйдәләр).

2. Дәгъваны карау актының дубликатын алу өчен түбәндәгеләр тапшырыла:

а) 1) гариза:

кәгазь чыганакта документ формасында (әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә). Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә һәм Идарә бүлекләренә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин;

Бердәм портал яки Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә туры китереп имзаланган электрон

формада (тиешле мәгълүматларны интерактив формага кертү юлы белән тутырыла). Гариза формасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең рәсми сайтында күчермәсен алу һәм тутыру өчен электрон формада урнаштырылган;

б) мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ (гариза биргәндә күрсәтелә);

в) мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр документлар вәкил тарафыннан тапшырылса).

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

1) Идарә бүлекләренә шәхсән яисә почта аша кәгазь чыганакларда;

2) КФҮ аша кәгазь чыганакларда.

Гаризаны тапшырган вакытта мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктән гаризаның кабул ителүен раслый торган теркәү номеры белән язу бирелә;

3) Бердәм портал аша;

4) Республика порталы аша.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документ рәвешендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Мөрәҗәгать итүчене идентификацияләү һәм аутентификацияләү «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» (алга таба – ИАБС) федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып гамәлгә ашырыла.

Гаризага теркәлеп бирелә торган электрон документлар (документларның электрон рәвешләре), шул исәптән ышаныч кәгазьләре 50 Мбайттан артмаган үлчәмдә pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларындагы файллар рәвешендә җибәрелә.

Электрон документларның (электрон документ рәвешләренең) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә уку һәм документ реквизитларын тану мөмкинлеген бирергә тиеш.

### 2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар

1) дәүләт пошлинасын түләү факты турында белешмәләр (Татарстан Республикасы Федераль казначылык идарәсендә);

2) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан юридик зат турында яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан шәхси эшкуар турында өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.

Тапшырылган документларда билгеләнгән тәртиптә танытыкланмаган чистартылган, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм алдан әйтелмәгән башка, шулай ук карандаш белән ясалган, төзәтмәләр булуы.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең исемлеге тулы булып тора.

2.7.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Регламентка 4 нче кушымтада билгеләнгән формага туры китереп рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетка һәм (яки) күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

2.7.4. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Бердәм порталда, Республика порталында, Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең рәсми сайтында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;
2) дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен җыем түләү турында мәгълүмат булмавы;
3) үзйөрешле техниканың һәм җайланманың тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәве;
4) эксплуатацияләү буенча гарантия срогының тәмамлануы.

2.8.3. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең электрон почта адресы буенча җибәреп яки Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә шәхсән мөрәҗәгать итеп, ирекле формада язылган язмача гариза нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтелүдән баш тартырга хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтелүдән баш тарту турында кире алынган гариза нигезендә Дәүләт

техник күзәтчелек идарәсенең вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителә. Мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) дәүләт хезмәте күрсәтелүдән баш тарту факты, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карарны теркәп, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәлә.

2.8.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар, сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Регламентка 5 нче кушымтада билгеләнгән формага туры китереп рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетка һәм (яки) күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

2.8.5. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Республика порталында, Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела

### 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүле нигездә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җыем Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 23.12.2016 ел, №7-22/т карары белән билгеләнгән күләмдә алына һәм Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе сайтында урнаштырылган.

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә хезмәт күрсәткән өчен җыем күләме 237 сум тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын түләү һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә алына торган башка төрле түләүләрне түләү Бердәм порталдан, Республика порталыннан һәм Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең рәсми сайтыннан файдаланып гамәлгә ашырылмый.

Дәүләт пошлинасын күчерү өчен кирәкле реквизитлар белән квитанция бланкын мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе бүлеге инспекторыннан яки Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең рәсми сайтыннан алырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документка Идарә бүлегенең вазыйфаи заты, КФҮ хезмәткәре гаебе белән җибәрелгән хаталарны төзәтүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелгән очракта, мөрәҗәгать итүчедән түләү алынмый.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык булырга тиеш түгел. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

## 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

Гариза алынган көннән соң бер көн эчендә теркәлә.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан КФҮ аша тапшырылган гариза Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе бүлегендә билгеләнгән тәртиптә КФҮ аша алынган көнне теркәлә.

Бердәм порталга, Республика порталына электрон рәвештә кергән гариза кергән көнендә теркәлә.

Ял (бәйрәм) көнендә, эшләми торган вакытта электрон формада кергән гариза икенче эш көненә теркәлә.

## 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза үрнәкләре урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе һәм Идарә бүлекләре, Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе һәм Идарә бүлекләре биналарына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу урыннары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм этнең махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булган очракта, бинага һәм бүлмәләргә озата йөри торган этне кертү;

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе һәм Идарә бүлекләре хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүгә комачаулаучы каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.

2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

### 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе, Идарә бүлекләре биналарының җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе бинасын, Идарә бүлмәләрен инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеген бирә торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү, шулай ук инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеген бирә торган башка шартлар үтәлешен тәэмин итү;

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе һәм Идарә бүлекләре хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, аларга хезмәт күрсәтүгә комачаулый торган, инвалидлар өчен биналардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле булмаган башка каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе, Идарә бүлекләре белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозылуына карата нигезле шикаятьләрнең булмавы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бинаның һәм бүлмәләрнең инвалидлар өчен файдалана алырлык булуы һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең файдалана алырлык булу күрсәткечләренә ирешү;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең һәм Идарә бүлекләренең вазыйфаи затлары белән үзара хезмәттәшлек итү саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

барлык кирәкле документлар белән гариза тапшырылганда, – бер тапкыр;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алган очракта, – бер тапкыр.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер мәртәбә үзара бәйләнешкә керү вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче КФҮ, КФҮ ерактагы эш урыннарына мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ белгече, КФҮ ерактагы эш урыннарындагы белгечләр консультацияли һәм документларны кабул итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда, Республика порталында, КФҮ (КФҮ аша хезмәт күрсәтүгә гариза биргән очракта) алынырга мөмкин.

### 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә түбәндәге мәгълүмат системалары кулланыла:

«Гостехнадзор Эксперт» төбәк мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

Комплекслы рәсми мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтү каралмаган.

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең рәсми сайтында урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары

### 3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә дә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза төзү өлешендә;

КФҮ, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, Идарә бүлекләренә язмача мөрәҗәгать иткәндә алынган гаризаны кабул итү һәм теркәү;

ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

тапшырылган документларны һәм белешмәләрне тикшерү;

комиссия тарафыннан үзйөрешле машинаны яки җайланманы карау;

нәтиҗә әзерләү;

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.1.2 Техник хаталарны төзәтү.

### 3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза төзү өлешендә

3.2.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүе административ процедураны башкару өчен нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып түбәндәгеләр тора:

- мөрәҗәгать итүче КФҮ мөрәҗәгать иткәндә – КФҮ хезмәткәре;
- мөрәҗәгать итүче Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә, Идарә бүлекләренә мөрәҗәгать иткән очракта – вазыйфаи затлар.

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация сорап, күпфункцияле үзәккә шәхсән үзе һәм телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә дә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәк (http://mfc16.tatarstan.ru/) сайтыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә консультацияләү.

3.2.3. Мөрәҗәгать итүче Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә һәм/яки Идарә бүлекләренә шәхсән, телефон һәм электрон почта буенча мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле башка мәсьәләләр буенча да, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе сайтыннан консультация алырга хокуклы.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

## 3.3. Дәгъваны карау актын бирү

3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны күпфункцияле үзәк аша яки күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша кабул итү.

3.3.1.1. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза белән күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итә һәм Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

3.3.1.2. Гаризаларны кабул итүче күпфункцияле үзәк хезмәткәре:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый;

мөрәҗәгатьнең предметын билгели;

документлар тапшыручы затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасында (алга таба – КФҮ АМС) гаризаның электрон формасын тутыра;

Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кәгазьдә тапшырылган очракта, тапшырылган документларны сканер аша уздыра;

Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан гаризаны бастырып чыгара;

тикшереп чыгу һәм имзалау өчен мөрәҗәгать итүчегә бирә;

имзаланганнан соң имзаланган гаризаны Автоматлаштырылган мәгълүмат системасына сканер аша кертә;

электрон формада тапшырылган документларны яки документларның сканер аша уздырылган электрон үрнәкләрен Автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертә, электрон эш формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның оригиналларын кире кайтара;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү буенча язу бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: җибәрүгә әзер гариза һәм документлар пакеты.

3.3.1.3. Күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчедән кабул ителгән электрон формадагы (электрон эшләр пакетлары составында) документлар пакетын мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәкнең структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән башлап бер эш көне эчендә Идарәгә тапшыра.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: электрон багланышлар системасы аша Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон эш).

3.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада кабул итү.

3.3.2.1. Гаризаны электрон формада тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

авторизация уза;

электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.5.2 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: электрон багланышлар системасы аша Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә җибәрелгән электрон эш.

3.3.3. Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе тарафыннан документлар комплектын карау.

3.3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларның алынуы административ процедура үтәлешен башлау нигезе булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат булып Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе бүлегенең баш дәүләт инженер-инспекторы (алга таба – документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.

3.3.3.2. Мөрәҗәгать итүче гариза белән Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә мөрәҗәгать иткән очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

мөрәҗәгатьнең предметын билгели;

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели;

документлар тапшыручы затның вәкаләтләрен тикшерә;

тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә (документларның күчермәләренең тиешенчә рәсмиләштерелүен, документларда чистартылган, өстәп язылган, сызылган сүзләрнең һәм алдан сөйләшенмәгән төзәтмәләр булмавын тикшерә);

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү буенча язу бирә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат мөрәҗәгать итүчегә гаризаны кабул итү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

3.3.3.3. Документлар карау өчен алынганнан соң документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм «Документларны тикшерү» статусын беркетә, ул Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла;

алынган электрон эшләрне, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон формада теркәлгән документларны һәм документларның электрон үрнәкләрен өйрәнә;

документларның электрон үрнәкләренең комплектлылыгын, укылышлы булуын тикшерә;

Бердәм порталга керү юлы белән, электрон имзаның чын булу шартлары үтәлешен тикшерә (әгәр мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон үрнәкләре тапшырылган булса).

Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты әзерли.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның чын булу шартларының үтәлмәве ачыкланса, баш тарту турындагы карар

проектында аны кабул итү өчен нигез булган 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясындагы пунктлары булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре мондый документларга белдерелә торган таләпләрне бозуга бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту нигезләрендә тапшырылмаган, дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләре булган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән документларның (мәгълүматның, белешмәнең) атамасы турында мәгълүмат күрсәтелергә тиеш), килештерү өчен билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы ярдәмендә җибәрелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проектын килештерү әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат гариза алынган көннән соң бер эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә гаризаның алынуы турында теркәү номеры, гаризаны алу датасы, үзенә килгән документларның файллары атамалары исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу датасы күрсәтелгән белдерү җибәрә.

3.3.3.4. Регламентның 3.3.3.3 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.3.3.5. Регламентның 3.3.3 пунктында билгеләнә торган процедуралар гариза карау өчен алынган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: карап тикшерүгә кабул ителгән документлар комплекты яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.4.1. Идарә бүлегенең баш дәүләт инженер-инспекторы ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә, түбәндәгеләрне бирү турында:

1) дәүләт пошлинасын түләү факты турында белешмәләр (Татарстан Республикасы Федераль казначылык идарәсендә);

2) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан юридик зат турында яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан шәхси эшкуар турында өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә).

Регламентның әлеге пунктчасында билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документларны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматларны) бирә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматларның булмавы турында белдерү җибәрә.

Шушы пунктчада билгеләнә торган процедура законнарда билгеләнгән чорларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә бүлегенә җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яки баш тарту турында белдерү.

3.5. Тапшырылган документларны һәм белешмәләрне тикшерү.

Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы алынган документларны һәм белешмәләрне тикшерә.

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә үзйөрешле машиналар һәм җайланмалар хуҗаларының дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен Регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр ачыкланган очракта, Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә үзйөрешле машиналар һәм җайланмалар хуҗаларының дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә язмача хат әзерли.

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә үзйөрешле машиналар һәм җайланмалар хуҗаларының дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, баш дәүләт инженер-инспекторы үзйөрешле техниканы яки җайланманы карауда катнашу турында карар кабул итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла

Процедураларның нәтиҗәсе: баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булуы (булмавы) турында карар кабул итү, дәүләт хезмәтләренә баш тарту турында хәбәр бирү (җибәрү).

3.5.1. Комиссия тарафыннан үзйөрешле машинаны яки җайланманы карау.

Баш дәүләт инженер-инспекторы, машинаның хуҗасы һәм тәэмин итүче предприятие (әзерләүче яки сервис оешмасы) вәкиле катнашында гарантияле, аварияле техниканы карау эше башкарыла.

Техниканы караганнан соң баш тарту сәбәбе, гаепле як, торгызу өчен кирәкле төеннәр һәм детальләр, торгызу бәясе һәм эшсез торган вакытны исәпкә алып, китерелгән гомуми зыян күләме ачыклана.

Дәгъваны карау нәтиҗәләре буенча дәгъваны карау акты төзелә.

Идарә бүлеге вәкиле үз ягыннан дәгъваны карау актына имза сала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәгъваны карау турында Идарә вәкиле тарафыннан имзаланган акт.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.6.1. Дәгъваны карау акты өч нөсхәдә төзелә һәм мөрәҗәгать итүчегә, Идарә бүлегенең баш дәүләт инженер-инспекторына, тәэмин итүче предприятие (әзерләүче яки сервис оешмасы) вәкиленә техникадан баш тартуларны исәпкә алу журналында имза куйдыртып бирелә.

Мөрәҗәгать итүче КФҮ аша мөрәҗәгать иткән очракта көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон рәвеше җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүче Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына автомат рәвештә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон рәвеше җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карау уздырылган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәгъваны карау турында тапшырылган акт.

3.6.2. Югалган яки яраксызга килгән дәгъваны карау актының дубликатын бирү (бирүдән баш тарту)

3.6.2.1. Гариза кабул итү.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән кәгазьдә яисә электрон формада Бердәм портал, Республика порталы аша Идарә бүлегенә, әлеге Регламентның 2.6.1 пунктчасы нигезендә, документларны теркәп, югалганы яки яраксызланганы урынына алмашка дәгъваны карау акты дубликатын бирү турында гариза (алга таба – гариза) тапшыра, түбәндәге очракларда:

дәгъваны карау акты югалган очракта, яисә дәгъваны карау акты алга таба файдалану өчен яраксыз булса.

Югалган яки файдалану өчен яраксыз булган дәгъваны карау акты дубликатын бирү турында гаризаны кабул итү, теркәү, документларны тикшерү әлеге Регламентның 3.3 пунктчасы нигезендә башкарыла.

3.6.2.2. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

Ведомствоара оешмаларга рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү һәм алардан җавап алу әлеге Регламентның 3.4 пунктчасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6.2.3. Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы кергән документларны һәм белешмәләрне 3.5 пунктча нигезендә тикшерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мәгълүматлар алынганнан соң 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

3.6.2.4. Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы мөрәҗәгать итүчегә дәгъваны карау акты дубликатын кул куйдыртып тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәгъваны карау актының дубликатын бирү.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән кәгазьдә яисә электрон формада Бердәм портал, Республика порталы аша баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән техник хаталарны (язу, басма хаталарны яки грамматик ялгышларны) бетерү турында гариза тапшырыла.

Үзгәртеп рәсмиләштерү эше мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан бирелгән, техник хатасы булган документны теркәп теркәүгә алынган, әлеге Регламентка 2 нче кушымтадагы гариза нигезендә гамәлгә ашырыла.

Баш дәүләт инженер-инспекторы:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм гаризаларны теркәү журналында терки;

техник хатасы булган документны үзгәртеп рәсмиләштерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, үзгәртеп рәсмиләштерелгән документ.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлешен һәм башкарылуын даими тикшерүдә тоту Идарә җитәкчесе, Идарә җитәкчесе урынбасары һәм дәүләт хезмәте күрсәтү эшен оештыру өчен җаваплы булган зат тарафыннан башкарыла.

4.2. Агымдагы контрольлек Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендәге вазыйфаи затларның Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнардагы (Регламенттагы) таләпләргә туры килү-килмәвенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр бирү сроклары һәм тәртибе үтәлешенә.

4.3. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә дәүләт хезмәтен башкарганда Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең вазыйфаи затлары тарафыннан җибәрелгән хокук бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар закон нигезендә дисциплинар җаваплылыкка тартыла.

4.4. Регламент үтәлешенә гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан контрольдә тоту Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән, шулай ук Регламентны үтәү барышында гамәлгә ашырыла торган (кабул ителгән) гамәлләргә (гамәл кылмауны) һәм карарларга югары торучы дәүләт хакимияте органнарына шикаять белдерү юлы белән дә гамәлгә ашырыла.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган КФҮ, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1' өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе (Идарә бүлекләре) хезмәткәрләре, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган КФҮ, КФҮ хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

Идарә бүлекләре хезмәткәрләре карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе җитәкчесенә бирелә.

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр әлеге КФҮ җитәкчесенә тапшырыла.

КФҮ карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр КФҮ оештыручы тарафыннан бирелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче гаризасын, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) $15^1$ статьясында күрсәтелгән гаризаны теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи зат, дәүләт хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең https://gtn.tatarstan.ru рәсми сайтыннан, Бердәм порталдан (http://www.gosuslugi.ru/), Республика порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru) файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта буенча, «Интернет» челтәреннән, КФҮ рәсми сайтыннан, Бердәм порталдан (http://www.gosuslugi.ru/), Республика порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru) файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында да алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә граждан хезмәткәренең, КФҮ, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе алынган шикаять алынган көненнән соң икенче эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң 15 эш көне эчендә, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип танылган очракта, әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Сатылган яки төзәтелгән
техниканың тиешле сыйфатта
булмавына бәйле рәвештә
үзйөрешле техника һәм җайланма
хуҗалары дәгъвалар карау
комиссияләрендә катнашу буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

Дәүләт техник күзәтчелек
бүлеге башлыгына ________________________________

Баш дәүләт инженер-инспекторга ________________________________

Кемнән ________________________________

(милекченең фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта), оешманың тулы атамасы)

Салым түләүченең тәңгәллек номеры: ________________________________

Адрес: ________________________________

(физик затның яшәү урыны буенча адресы, юридик затның урнашкан урыны буенча адресы)

Телефон: ________________________________

**Сатылган яисә ремонтланган техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә үзйөрешле машиналар һәм җайланмалар хуҗаларының дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза**

Үзйөрешле техника һәм җайланма хуҗасының сатылган яисә төзекләндерелгән техниканың тиешсез сыйфатына бәйле дәгъвасын карауда катнашуны сорыйм

| № | Үзйөрешле машина атамасы, маркасы | Дәүләт теркәвенә алу тамгасы | Рамасының завод куйган номеры | Двигателенең номеры |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| 3 | | | | |
| 4 | | | | |

______________________________________________________________________________

________ сум күләмендә дәүләт техник күзәтчелек хезмәтләре өчен түләү турында 20___ елның «__» ____________ № ____ квитанция.

**Тикшерү уздыру турында мәгълүмат**

*Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутырыла:*

Үзйөрешле техниканы һәм җайланманы
түбәндәге адрес буенча карауны сорыйм: ______________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Тикшерү үткәрү датасы:
__________________________________________________________________

Үзйөрешле техниканы һәм җайланманы карап чыгу түбәндәгеләргә ышанып тапшырыла:
________________________________________________
____________________________________________

______________________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), ышаныч кәгазе, элемтә өчен телефон)

______________________________________________________________________________

Дата «___» _____________ 20___ ел

Мөрәҗәгать итүченең имзасы,
(предприятие җитәкчесе урынбасары): ____________ _______________________
Мөһер урыны (фамилия, инициаллар)
булган очракта

**Гаризаны кабул итү турында тамга**

Дата: «____»___________ 20____ ел.

Дәүләт техник күзәтчелек инженер-инспекторы: ________________________________
Имза:______________

Тикшерү уздыруның килештерелгән датасы һәм вакыты:
________________________________________

Үзйөрешле техниканы һәм җайланманы карауны Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Дәүләт инженер-инспекторы уздырды: ______________________ ______________

(имза) (фамилия, инициаллар)

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә үзйөрешле техника һәм җайланма хуҗалары дәгъвалар карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе ________________________________
бүлеге җитәкчесе
Баш дәүләт инженер-
инспекторына____________________________________________________
Кемнән ___________________________________________________________________
(милекченең фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта), оешманың тулы атамасы)
Салым түләүченең тәңгәллек номеры:____________________________________
Адрес:____________________________________________________________________
(физик затның яшәү урыны буенча адресы, юридик затның урнашкан урыны буенча адресы)
__________________________________________________________________________
Телефон:__________________________________________________________________

## ГАРИЗА

Баш дәүләт инженер-инспекторы җибәргән техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яисә арифметик хатаны) бетерүегез турында үтенәм:

| № | Үзйөрешле машина атамасы, маркасы | Дәүләт теркәвенә алу тамгасы | Рамасының завод куйган номеры | Двигателенең номеры |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |

Дата: «___» ___________ 20___ел.

Мөрәҗәгать итүченең имзасы,
(предприятие җитәкчесе урынбасары): __________ ________________________
(фамилия, инициаллар)

### Гаризаны кабул итү турында тамга

Дата: «___» ___________ 20___ел.

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең дәүләт инженер-
инспекторы:______________________________
(фамилия, инициаллар)
Имза:________________________

Сатылган яки төзәтелгән
техниканың тиешле сыйфатта
булмавына бәйле рәвештә
үзйөрешле техника һәм җайланма
хуҗалары дәгъвалар карау
комиссияләрендә катнашу буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

# ДӘГЪВАЛАРНЫ КАРАУ АКТЫ

Акт төзелгән урын

______________________________________________

хуҗа, физик зат вәкиленең, вәкилнең (юридик зат) фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта), почта адресы

______________________________________________

Түбәндәгеләр составындагы комиссия тарафыннан төзелде:

тәэмин итүче (әзерләүче) предприятие вәкиле:

______________________________________________

______________________________________________

фамилия, исем, ата исеме (булган очракта), вазыйфа

Дәүләт техник күзәтчелек инспекциясе вәкиле

______________________________________________

______________________________________________

фамилия, исем, ата исеме (булган очракта), вазыйфа

хуҗа вәкиле

______________________________________________

фамилия, исем, ата исеме (булган очракта), вазыйфа

машинага яки җайланмага

______________________________________________

Маркасы ______________________ **төзәтү датасы** ______________________

эксплуатациягә кертү датасы (сатканнан соң, төзәткәннән соң)

______________________________________________

Тәэмин итүче предприятие (әзерләүче, сервис оешмасы)

завод номеры

двигателенең номеры

эксплуатациягә керткән вакыттан башлап машина эшләгән

сәгать (көн)

Эшләгәндә

эшләр тибын күрсәтергә

Машинаның яки җайланманың төзексезлеге түбәндәгедә чагылды

*Эксплуатация кагыйдәләрен бозулар ачыкланды*

Комиссия нәтиҗәсе

Машинаны яки җайланманы торгызу чыгымнары түләнерргә тиеш

Машинаны яки җайланманы торгызу өчен түбәндәге агрегатларны (төеннәрне, детальләрне) алмаштырырга кирәк

агрегатларның (төеннәрнең, детальләрнең) аталышы, каталог буенча №ы

Тәэмин итүче предприятие (әзерләүче) түбәндәге адреска китерергә тиеш

түбәндәге агрегатларны (төеннәрне, детальләрне)

Тәэмин итүче предприятие (әзерләүче, сервис оешмасы) вәкиле

«_____»___________20__ ел. ____________

имза

Хуҗа вәкиле

«_____»___________20__ ел. _____________

имза

Дәүләт техник күзәтчелек инспекциясе вәкиле

«_____»___________20__ ел. ____________

имза

Комиссиянең башка вәкилләре

«_____»___________20__ ел. _____________

имза

Машинаны яки җайланманы торгызу эшләре ______________ (дата) тәгәлләнде

Төзәтелгән машина яки җайланма хуҗасына _______________ (дата) кайтарып бирелде

Тәэмин итүче (әзерләүче, сервис оешмасы)

вәкиле________________________________

имза

Хуҗа вәкиле

________________________________________

имза

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә үзйөрешле техника һәм җайланма хуҗалары дәгъвалар карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

(Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе бланкы)

Кемгә

*(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))*

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар

Дата ____________ №____________

____________________________________________ (*мөрәҗәгать итүче*) __________________ №__________ мөрәҗәгатен караганда Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләренең техник торышына күзәтчелек идарәсенең Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә үзйөрешле техника һәм җайланма хуҗалары дәгъвалар карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының 2.7 пункты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде, чөнки: _____________________________________________________

(*баш тартуны нигезләү*)

Өстәмә рәвештә хәбәр итәбез: ______________________________________
(*баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук, булган очракта, башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә*).

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап, кабат мөрәҗәгать итү өчен каршылык булып тормый.

Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

(*карар кабул итүче органның вәкаләтле затының вазыйфасы*) *(имза) (Фамилия, исем, ата исеме (булган очракта))*

Сатылган яки төзәтелгән техниканың
тиешле сыйфатта булмавына бәйле
рәвештә үзйөрешле техника һәм
җайланма хуҗалары дәгъвалар карау
комиссияләрендә катнашу буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
5 нче кушымта

(Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе бланкы)

Кемгә

*(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))*

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар

_________________________________________ (*мөрәҗәгать итүче*) ________________ №__________ (*дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаның номеры*) мөрәҗәгатен караганда Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләренең техник торышына күзәтчелек идарәсенең Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә үзйөрешле техника һәм җайланма хуҗалары дәгъвалар карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының 2.8 пункты нигезендә Сезгә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылды, чөнки: ______________________________________________________

(*баш тартуны нигезләү*)

Өстәмә рәвештә хәбәр итәбез:

____________________________________________________________________

(*баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук, булган очракта, башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә*).

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап, кабат мөрәҗәгать итү өчен каршылык булып тормый.

Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

(*карар кабул итүче органның вәкаләтле затының вазыйфасы)*

*(имза) (Фамилия, исем, ата исеме (булган очракта))*

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә үзйөрешле техника һәм җайланма хуҗалары дәгъвалар карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе.

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Идарә башлыгы | 221-77-85 | gostehnadzorrt@mail.ru |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм кулланучылар базары идарәсе башлыгы | 264-77-15 | prav@tatar.ru |